| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«16» март 2026 ел № 292

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауның озак сроклы республика адреслы программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 1120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 03 октябрендәге 1120 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауның озак сроклы республика адреслы программасын гамәлгә ашыруның 2026-2028 елларга кыска сроклы планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2026 елда Кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләменең IV бүлегенең II абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

94648903,87 сум, шул исәптән:

Фонд акчалары – 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 28360903,87 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 сум;

ТСЖ, ТК, ТКХ әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре – 55000000,00 сум.

- IV бүлекне 2026 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең финанс чыганаклары ихтыяҗлары күләмен яңа редакциядә бәян итәргә:

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сумнарда |
|---|---|
| Түбә ремонтлау | 25844339,0 |
| Вентиляция шахталарын һәм morҗаларны ремонтлау | 3505368,0 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, шул исәптән: | 28114116,83 |
| электр белән тәэмин итү | 15448451,0 |
| җылылык белән тәэмин итү | 0,00 |
| су белән тәэмин итү | 4789153,0 |
| Суны агызып җибәрү | 7016513,0 |
| газ белән тәэмин итү | 860000,0 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | 21688557,0 |
| Подвал бүлмәсен ремонтлау | 4105000,0 |
| Проект документациясенә дәүләт экспертизасын эшләү һәм уздыру | 10450000,0 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 941523,30 |
| Барлыгы | 94648903,87 |

2. Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча озак сроклы Республика адреслы программасы кысаларында эшләр төрләрен әлеге Карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.К. Габдуллин